Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының егерме бишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

8 сентябрь, 2022 ел № 187

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башлыкларының, муниципаль район башлыгы урынбасарының, контроль-хисап палатасы рәисе һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 2022 елның 1 октябреннән «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлек башлыкларының, муниципаль район башлыгы урынбасары, контроль-хисап палатасы рәисе һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» 2021 елның 1 апрелендәге 63 номерлы карары белән расланган айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга (үзгәрешләр белән, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2022 елның 30 мартындагы 152 номерлы карары белән расланган).

2. 2022 елның 1 октябреннән «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлек башлыкларының, муниципаль район башлыгы урынбасары, контроль-хисап палатасы рәисе һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» 2021 елның 1 апрелендәге 63 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфалары вазыйфа окладлары күләмнәрен арттырырга» (үзгәрешләр белән, Татарстан Республикасы

Питрәч муниципаль районы Советының 2022 елның 30 мартындагы 152 номерлы карары белән расланган).

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кечє төркеме белгече вазифа оклады күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов